ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.05.2020 с. Русское Макулово 13

Муниципаль мөлкәтне электрон
формада милеккә сату буенча аукцион
оештыру һәм үткәрү турында

Муниципаль мөлкәтне нәтиҗәле файдалану максатыннан 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы «Көндәшлекне яклау турында» Федераль законга, 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль милекне электрон формада сатуны оештыру һәм үткәрү турында» 2012 елның 27 августындагы 860 номерлы карарына, Россия Федерациясе Граждан кодексына таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Муниципаль мөлкәтне электрон формада милеккә сату буенча бәяне арттыруга ачык аукцион үткәрергә:

мәйданы 136,4 кв. м., кадастр номеры №16:15:110101:207, исеме - ашханә, катлар саны, шул исәптән җир асты катлары саны - 1, Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Макыл авылы адресы буенча урнашкан торак булмаган бина;

мәйданы 702 кв. м., кадастр номеры №16:15:110107:97 булган объект, җирләр категориясе – торак пункт җирләре, җәмәгать туклануы-куллану рөхсәт ителгән, Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Макыл авылы җирлеге, Рус Макылы авылы, Набережная урамы адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге .

2. Әлеге карарның 1 пунктында каралган муниципаль мөлкәткә милекне сату бәяләрен арттыруга аукцион үткәрү буенча аукцион комиссиясе составын Кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән муниципаль милекне сатуның башлангыч бәясен, шәхси эшмәкәр Корчагина Л. А. күчемсез милек объектының базар бәясен билгеләү турында үткәргән бәйсез бәяләү нигезендә, (10.05.202005 ел, 10.05.2005 ел, отчет), 175343 сум күләмендә (йөз җитмеш биш мең кырык өч сум) билгеләргә, шул исәптән:

торак булмаган бина өчен 92700 (туксан ике мең җиде йөз) сум,

җир кишәрлеге өчен 82643 (сиксән ике мең алты йөз кырык өч) сум.

4. Әлеге карарның 3 пунктында каралган башлангыч бәянең 5 (биш) проценты күләмендә «Аукцион адымы» билгеләргә.

5. Аукционда катнашучылар өчен беренче түләү суммасын әлеге карарның 3 пунктында каралган башлангыч бәянең 20 (егерме) проценты күләмендә расларга.

6. Аукцион үткәрү турында мәгълүматны Россия Федерациясенең www.torgi.gov.ru - рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт заказы агентлыгы» акционер җәмгыятенең sale.zakazrf.ru электрон мәйданчыгында һәм Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Муниципаль мөлкәткә милекне сату буенча бәяне арттыруга үткәрелгән электрон аукцион нәтиҗәләре буенча аукционда җиңүче белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән муниципаль милекне сату - алу шартнамәсе төзергә.

Макыл авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Р. Цветкова

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020 елның 20 маендагы
13 номерлы  карарына кушымта

Муниципаль мөлкәтне милеккә сату буенча аукцион комиссиясе составы:

Комиссия рәисе:

| | |
|---|---|
| Цветкова Лилия Рашидовна | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Матвеева Алина Ильшатовна | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге башлыгы |
| Валеева Людмила Михайловна | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетының баш хисапчысы |